МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Руководителям отделов (управлений) образования исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении республиканских чтений, посвященных изучению наследия великого татарского поэта Г.Тукая

**Уважаемые руководители!**

Во исполнение государственной программы Республики Татарстан «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014-2020 годы» Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с МУ «Управление образования» исполнительного комитета Арского муниципального района и Литературным музеем Габдуллы Тукая г.Казани **14-15 апреля 2016 года** в Республике Татарстан проводятся республиканские Тукаевские чтения (далее – Чтения).

В связи с празднованием 130-летия со дня рождения великого поэта Г.Тукая и с целью формирования духовно-нравственного воспитания и популяризации идей просветителя в образовательном процессе в текущем году Чтения проводятся в течение двух дней, отдельно для учащихся и учителей. Открытие традиционно состоится в МБОУ «Ново-Кырлайская средняя общеобразовательная школа» Арского муниципального района 14 апреля 2016 года, закрытие - в Литературном музее Габдуллы Тукая 15 апреля 2016 года. Исходя из этого, разработаны Положения, предусматривающие участие в Чтениях обучающихся 8–11 классов и учителей общеобразовательных организаций Республики Татарстан.

Для участия в Чтениях необходимо направить работу и заявку по установленному образцу в срок до 20 марта 2016 года по указанным в Положении адресам с пометкой «Чтения» и указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Ответственность за жизнь и здоровье школьников в пути следования и во время мероприятия необходимо возложить на сопровождающих педагогов.

Приложение: на 6 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра**
**Республики Татарстан – министр** **Э.Н.Фаттахов**

Л.Р.Зайнуллина
(843) 294 95 10



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Приложение № 1

## V Республикакүләм укучылар өчен
## Габдулла Тукай укуларының НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### I. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлгеге нигезләмә V Республикакүләм укучылар өчен Габдулла Тукай укуларын үткәрү тәртибен билгели.

1.2. V Республикакүләм Габдулла Тукай укулары (алга таба — Укулар) «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

### II. Укуларның максаты

Габдулла Тукай иҗатын һәм аңа бәйләп хәзерге заман әдипләренең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау; укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләре формалаштыру; халкыбызның тарихы, мәдәнияте, милли үзенчәлекләре белән кызыксындыру тудыру; укучыларда әдәби иҗатка омтылыш тәрбияләү, сәләтле балаларның иҗади эшләренә бәя бирү һәм аларны бүләкләү.

### III. Укуларны оештыручылар

3.1. Укуларны оештыручылар:

- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе;
- Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе».
- Габдулла Тукай әдәби музее – Татарстан Республикасы Милли музее бүлеге.

### IV. Укуларда катнашучылар

Укуларда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының VIII–XI сыйныф укучылары катнаша ала.

### V. Укуларның эш юнәлешләре

- Габдулла Тукай- күпкырлы шәхес
- Габдулла Тукай иҗаты иллюстрацияләрдә
- Г.Тукайның дуслары-фикердәшләре
- Казаныбызда Тукайга бәйле истәлекле урыннар

▪ «Тукай рухы һәрчак күңелдә» (укучылар тарафыннан иҗат ителгән Г.Тукай турында төрле жанрдагы әсәрләр)

▪ Г.Тукайның бер әсәрен сәхнәләштерү. Видеолар электрон вариантта кабул ителә. Регламенты 5-10 минут. I-III урынны алган коллективлар йомгаклау турына чакырылалар.

*Хезмәтләр татар телендә кабул ителә. Эш юнәлешләрендә бирелгән темаларны гына сайлавыгыз сорала. Башка темаларга эшләр кабул ителми.*

## VI. Фәнни-гамәли эшләргә таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли эшләр, фәнни-эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

▪ эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman 14, интервал 1,5, уңнан – 1,5, сулдан – 2,5, астан – 2, өстән – 1,5) бит киңлеге буенча тигезләп, 1,25 мм кызыл юл калдырып, сүзләрне юлдан-юлга күчермичә, компьютерда җыелырга тиеш. Сылтамалар текст эчендә шакмак җәяләрдә китерелә [1:182].

▪ текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Эшләр бары тик язмача вариантта гына кабул ителә. II турга үткән укучылар электрон вариантларны үзләре белән алып киләләр.

▪ эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр) булырга мөмкин.

▪ текст түбәндәге кагыйдәләрне истә тотып җыелырга тиеш: абзацтагы сүзләр бер генә ара (пробел) аша языла; тыныш билгеләре алдыннан ара (пробел) калдырылмый, тыныш билгесеннән соң бер ара (пробел) калдырыла; дефис (озын сызык) һәм сызыкча (кыска сызык) аерылырга тиеш.

▪ кулланылган әдәбият исемлеге текст азагында алфавит тәртибендә бирелә.

▪ эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

▪ титул битенә белем бирү оешмасының тулы исеме, районы, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

▪ кереш, төп өлешенең аерым бүлекләре, йомгак, әдәбият исемлеге яңа биттән башлана.

*Укуларга башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр һәм күрсәтелгән вакыттан соңрак җибәрелгән яки куелган таләпләргә җавап бирмәгән эшләр кабул ителми.*

**Гариза үрнәге**

| № т/б | Ф.И.Әтисенең исеме, туган елы | Район, мәктәп, сыйныф | Адрес, индекс | Паспорты буенча мәгълүмат: кем тарафыннан, кайчан бирелгән | Фәнни җитәкченең Ф.И.Әтисенең исеме | Элемтә өчен телефон номеры (районның коды) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Документ создан в электронной форме. № исх-284/16 от 05.02.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 4 из 9. Страница создана: 05.02.2016 18:20

***Материалны калыпка салу үрнәге***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*МБГБУ «Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе”*
*Марданова М.Р., 8 нче сыйныф укучысы*
*Габдулла Тукай төзегән җыентыкларның әдәбиятыбыз үсешендәге әһәмияте.*
*Укытучы: Зарипова М.Р., татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*Текст*
*Эчтәлек.*
*I.Кереш.*
*II. 1 нче бүлек.*
*2 нче бүлек.*
*III.Йомгаклау.*

*Кулланылган әдәбият*


*1. Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: Документаль роман. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000.-272 б.*

*2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.– Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2002.-511 б.*


## VII. Укуларны үткәрү тәртибе

7.1. Укулар түбәндә күрсәтелгән вакыт кысаларында үтә:

Эшләр заявка белән бергә **2016 нче елның 20 нче мартына кадәр** Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбенә почта аша (422035, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 нче йорт) яки zaripova-mil1967@mail.ru электрон адресына җибәрелә.

Элемтә өчен телефон – 8(84366) 5-67-36.

Габдулла Тукай укулары **2016 нче елның 14 нче апрелендә** Арча муниципаль районы Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе базасында үткәрелә.

Укуларда чыгыш ясау вакыты – 7 минутка кадәр. Катнашучы бирелгән вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирә белергә тиеш. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

## VIII. Укуларны йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Укуларда катнашучыларның фәнни-гамәли эшләрен һәм чыгышларын Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы приказы белән расланган җюри бәяли.

Укуларда җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары , Укуларда катнашучыларга шәһадәтнамә тапшырыла.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8 (84366) 56-7-36 (Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе), 8(84366) 3-30-12 (Арча районы мәгариф идарәсе), 8(84366) 3-22-98, 89274306556 (Мостафина Энҗе Габдулатҗан кызы), 8(84366) 5-67-36, 89179265485 – Зарипова Миләүшә Рафис кызы

Приложение № 2

**Республикакүләм укытучылар өчен**
**Габдулла Тукай укуларының НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## I. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлгеге нигезләмә Республикакүләм укытучылар өчен Габдулла Тукай укуларын үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Республикакүләм Габдулла Тукай укулары (алга таба — Укулар) «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

## II. Укуларның максаты

Габдулла Тукай иҗатын һәм аңа бәйләп хәзерге заман әдипләренең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау; сәләтле укытучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү.

## III. Укуларны оештыручылар

3.1. Укуларны оештыручылар:

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе;
- Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе»
- Габдулла Тукай әдәби музее – Татарстан Республикасы Милли музее бүлеге

## IV. Укуларда катнашучылар

Укуларда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучылары һәм галимнәр катнаша ала.

## V. Укуларның эш юнәлешләре

Укулар түбәндәге номинацияләр буенча оештырыла:

- Мәктәптә Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүдә методик традицияләр һәм заманчалык;
- Габдулла Тукай иҗаты һәм һәм эшчәнлегендә педагогик карашларның чагылышы.
- Укыту-тәрбия процессында музей мөмкинлекләреннән файдалану.

*Хезмәтләр татар телендә кабул ителә. Эш юнәлешләрендә бирелгән темаларны гына сайлавыгыз сорала. Башка темаларга эшләр кабул ителми.*

## VI. Фәнни-гамәли эшләргә таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли эшләр, фәнни-эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

▪ эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman 14, интервал 1,5, уңнан – 1,5, сулдан – 2,5, астан – 2, өстән – 1,5) бит киңлеге буенча тигезләп, 1,25 мм кызыл юл калдырып, сүзләрне юлдан-юлга күчермичә, компьютерда җыелырга тиеш. Сылтамалар текст эчендә шакмак җәяләрдә китерелә [1:182].

▪ Текстның күләме 5 басма биттән артмаска тиеш. Эшләр бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. II турга үткән укытучылар үзләре белән фәнни эшнең язма вариантын алып киләләр. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

▪ Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр) булырга мөмкин.

▪ Кулланылган әдәбият исемлеге текст азагында алфавит тәртибендә бирелә.

▪ Титул битенә белем бирү оешмасының тулы исеме, районы, укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

*Укуларга башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр һәм күрсәтелгән вакыттан соңрак җибәрелгән яки куелган таләпләргә җавап бирмәгән эшләр кабул ителми.*

Укуларда чыгыш ясау вакыты – 7 минутка кадәр. Катнашучы бирелгән вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирә белергә тиеш. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

*Гариза үрнәге*

| № т/б | Катнашучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме | Укытучының фәнни дәрәҗәсе | Шәһәр, район, мәктәп | Адрес, индекс | Электрон адрес | Элемтә өчен телефон номеры (районның коды) | Номинация |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

## VII. Укуларны үткәрү шартлары һәм тәртибе

Гаризалар һәм чыгышлар **2016 нче елның 20 нче мартына кадәр** түбәндәге электрон адрес буенча кабул ителә: tukay.ukulary@mail.ru.

*Уңышлы дип табылган эш авторларына аерым чакыру җибәрелә.*

Укытучылар өчен Габдулла Тукай укулары **2016 нче елның 15 нче апрелендә** Казан шәһәренең Габдулла Тукай әдәби музее базасында үткәрелә.

Документ создан в электронной форме. № исх-284/16 от 05.02.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 7 из 9. Страница создана: 05.02.2016 18:20
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Укуларда чыгыш ясау вакыты – 7 минутка кадәр. Катнашучы бирелгән вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирә белергә тиеш. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

## VIII. Укуларны йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Укуларда катнашучыларның фәнни-гамәли эшләрен һәм чыгышларын Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы приказы белән расланган җюри бәяли.

Укуларда җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары, 2 турга узучыларга шәһадәтнамәләр тапшырыла.

**Белешмәләр өчен: Г.Тукай әдәби музее (Казан)**

Телефоннар:

+7(843)293-17-66 Төхфәтова Гүзәл Фәрдин кызы, Г.Тукай әдәби музее мөдире

+7(843)293-17-50 Нәгыймуллина Резедә Вагыйз кызы, Г.Тукай әдәби музееның өлкән фәнни хезмәткәре

Лист согласования к документу № 2789-08 от 06.02.2016
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 05.02.2016 16:49

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 05.02.2016 - 20:29 | - |
| 2 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 05.02.2016 - 23:13 | - |
| 3 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 06.02.2016 - 07:12 | - |